СОВЕТ ШИШИНЕРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ШЕҢШЕҢӘР
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

---

РЕШЕНИЕ
31.10.2022ел

КАРАР
№ 54

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Шеңшеңәр авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым җыю һәм файдалану тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елгы № 131-ФЗ Федераль законның 56 статьясы, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Шеңшеңәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Шеңшеңәр авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1.Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шеңшеңәр авыл җирлеге территориясендә үзара салым җыю һәм гражданнарның үзара салымы тәртибе турындагы Шеңшеңәр авыл җирлеге Советының 11.04.2014 елгы № 105 нче карары белән расланган ( 06.02.2015 №131; 15.11.2017 ел, №64 редакциясендә) нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 5.1 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

"Җирле референдумда кабул ителгән карар нәтиҗәләрен игълан иткәннән соң,
18 яшькә җиткән барлык гражданнарга да үзара салым акчаларын түләүне өч ай эчендә башкарырга, яшәү урыны җирлек чикләрендә булган,җирле референдумда катнашуларына һәм тавыш биргәндә белдерелгән мөнәсәбәтләргә карамастан: 1 нче группа инвалидларга, балачактан инвалидларга, тулы булмаган гаиләләрдә балигъ булмаган балаларны тәрбияләүчеләргә, ялгызы яшәүче өлкән яшьтәге пенсионерларга, көндезге уку формасы буенча укучы студентларга, Россия Федерациясе кораллы көчләренә мобилизацияләнгән гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына үзара салым суммасының 50% күләмендә ташлама билгеләнгән; җирлек башкарма комитетының хәбәрнамәсе нигезендә җирлек башкарма комитетының банк реквизитларын, шулай ук түләү тәртибе турындагы мәгълүматны үз эченә ала.

2.Әлеге карар имзаланган көннән үз көченә керә.

3.Әлеге карарны районның baltasi.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Шеңшеңәр авыл җирлеге башлыгы Р.Х.Салихҗанов